МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 1789/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«12» 12 2025

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 28.11.2012 ел, № 17-131 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Рәсәй Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 19-21 статьялары, “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы һәм “Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында” 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының” Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында” 23.09.2025 ел, № 1375/о боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 08.12.2025 ел, № 10-53/15083 бәяләмәсен исәпкә алып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 28.11.2012 № 17- 131 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориаль планлаштыру схемасына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы 28.12.2018 № 44-258, 28.10.2022 № 28-222, 12.10.2023 № 37-299 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 Өлештә:

“Яңа Чишмә муниципаль районын территориаль планлаштыру буенча җирле (район) әһәмияттәге чаралар исемлеге” 1 бүлегенең “Социаль инфраструктураны үстерү чаралары” 1.2 пунктына территориаль планлаштыру турында Нигезләмәне, әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә “Күмү объектларын үстерү өлкәсендәге чаралар” 1.2.7 пунктчасы белән тулыландырырга;

әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә 1.2.7.1 таблицада күрсәтелгән “Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы. Җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасы” картасы өстәргә.

2. Территорияләрне үстерү департаментының агломерацияләрне үстерү идарәсенең көньяк-көнбатыш районнарны үстерү бүлегенә (А. С. Харитоновка):

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрү;

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыру;

әлеге боерыкны “Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны;

әлеге боерыкны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыру.

3. Юридик бүлеккә (Р.И. Кузьминга) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны территорияләрне үстерү департаментының агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А. Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары — В.Н. Кудряшев

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 12.12.2025 №1789/о боерыгы белән расланды

1.2.7.1 нче таблица

## 1.2.7. Күмү объектларын үстерү өлкәсендәге гамәлләр

### Муниципаль районның урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге күмү объектларының төрләре, билгеләнеше һәм исемнәре турында белешмәләр, аларның төп характеристикалары, урнашу урыны, шулай ук территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга характеристикалар, әгәр шушы объектларны урнаштыруга бәйле рәвештә мондый зоналарны билгеләү таләп ителсә

| № | Урнашу урыны | Объект исеме | Объектның билгеләнеше | Объектның статусы | Объектка характеристика | Гамәлгә ашыру срогы | Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зона |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Тубылгытау авыл җирлеге, 16:31:060205:130 җир кишәрлеге | Зират | Үлгәннәрне җирләү өчен шартлар тудыру | Урнаштыру планлаштырыла торган | 4,30 га | 2035 | Якынча санитар-яклау зонасы 50 м (12.5.2 пункты СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 “Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка объектларның санитар-яклау зоналары һәм санитар классификациясе”) |
| 2 | Шахмай авыл җирлеге, 16:31: 040201 кадастр кварталы чикләрендә | Зират | Үлгәннәрне җирләү өчен шартлар тудыру | Урнаштыру планлаштырыла торган | 0,15 га | 2035 | Якынча санитар-яклау зонасы 50 м (12.5.2 пункты СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 “Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка объектларның санитар-яклау зоналары һәм санитар классификациясе”) |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| 3 | Шахмай авыл җирлеге, кадастр кварталлары чикләрендә | Зират | Гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру | Урнаштыру планлаштырыла торган | 0,40 га | 2035 | Якынча санитар-яклау зонасы 50 м |

| № | Урнашу урыны | Объект исеме | Объектның билгеләнеше | Объектның статусы | Объектка характеристика | Гамәлгә ашыру срогы | Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зона |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 16:31:040303, 16:31:040506 | | үлгәннәрне күмү | | | | (СанПин, 12.5.2 нче пункт )2.2.1/2.1.1.1200-03 “Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка объектларның санитар-яклау зоналары һәм санитар классификациясе”) |
| 4 | Өтәшкә авыл җирлеге, ЗУ чикләрендә 16:31:070304: 275, 16:31:000000:700 җир кишәрлекләре | Зират | Үлгәннәрне җирләү өчен шартлар тудыру | Урнаштыру планлаштырыла торган | 1,00 га | 2035 | Якынча санитар-яклау зонасы 50 м (12.5.2 пункты СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 “Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка объектларның санитар-яклау зоналары һәм санитар классификациясе”) |

Искәрмәләр:

- объектның мәйданы якынча һәм проектлауның алдагы стадияләрендә үзгәрергә мөмкин;

Зиратны урнаштыру чараларын табигатьне саклау һәм санитария - эпидемиология законнары нормаларын һәм таләпләрен үтәгән очракта гына, шул исәптән: -Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 03 мартындагы 222 номерлы карары (алга таба - Кагыйдәләр) белән расланган санитар-яклау зоналарын билгеләү һәм санитар – яклау зоналары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалану кагыйдәләре таләпләренә туры китереп, якындагы нормалаштырыла торган объектларны исәпкә алып, санитар-яклау зоналарын оештыру һәм СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 “Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка объектларның санитар-яклау зоналары һәм санитар классификациясе”;

- Рәсәй Федерациясе Су кодексының 65 статьясындагы 15 өлеше нигезендә зиратларны су саклау зоналары һәм яр буе яклау полосалары чикләрендә урнаштыруны төшереп калдыру.

16:31:040201 Кадастр кварталы чикләрендә зиратны урнаштыру чарасын себер язвасы үләт базының якынча санитар-яклау зонасын кыскарту шарты белән (зират өчен участокны санитар-яклау зонасыннан төшереп калдыруны исәпкә алып) Кагыйдәләр таләпләре нигезендә яки Татарстан Республикасы Роспотребнадзор Идарәсе белән килештергәндә 1093 СанПин 3.3686-21 “Йогышлы авыруларны профилактикалау буенча санитар-эпидемиологик таләпләр”.

Зиратны җир кишәрлекләре чикләрендә урнаштыру эшләрен гамәлгә ашырганда 16:31:070304:275, 16:31:000000:700 газ бүлү челтәрләренең саклау зоналарын исәпкә алырга кирәк (инв газүткәргече № 7998) (реестр номеры 16:31-6.667) һәм ВЛ 10 кВ Ф.01 Ленино (реестр номеры) 16:31-6.665.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 12.12.2025 № 1789/о боерыгына
2 нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫН ТЕРРИТОРИАЛЬ ПЛАНЛАШТЫРУ СХЕМАСЫ.
1.2.7.1 ТАБЛИЦАСЫНДА КҮРСӘТЕЛГӘН ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ОБЪЕКТЛАРНЫ ПЛАНЛАШТЫРЫП УРНАШТЫРУ КАРТАСЫ

